**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3936**
**13.08.2020**

Башкарма комитетның
аерым карарларына
үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2020 елның иң яхшы дворнигы» исеменә шәһәр конкурсы үткәрү турында» 2020 елның 22 маендагы 2403 номерлы карары белән расланган «2020 елның иң яхшы дворнигы» исеменә шәһәр конкурсы үткәрү турында нигезләмәгә, 18 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«18. Шәһәр конкурс комиссиясенең карары конкурсның һәр катнашучысына карата ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш буенча кабул ителә һәм 2020 елның 14 августында комиссиянең утырышта катнашкан әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.».

2. Башкарма комитетның «2020 елның иң яхшы сантехнигы» исеменә шәһәр конкурсы үткәрү турында 2020 елның 22 маендагы 2405 номерлы карары белән расланган «2020 елның иң яхшы сантехнигы» исеменә шәһәр һөнәри осталык конкурсы үткәрү турында нигезләмәгә, 18 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«18. Шәһәр конкурс комиссиясенең карары конкурсның һәр катнашучысына карата ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш буенча кабул ителә һәм 2020 елның 14 августында комиссиянең утырышта катнашкан әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.».

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Ф.Ш. Салахов